ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 18 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяның 7 өлешендә «ул» сүзен төшереп калдырырга, «территориаль органыннан» сүзләреннән соң «муниципаль берәмлек уставы, муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый акт хакындагы белешмәләрне Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре уставларының дәүләт реестрына кертү турында «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 6 өлешендә каралган хәбәрнамә» сүзләрен өстәргә;

2) 15 статьяда:

а) 1 өлештә:

39 пунктта «Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә» сүзләрен «федераль закон нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 40 пункт өстәргә:

«40) элек исәпкә алынган күчемсез милек объектларына хокукы булган затларны ачыклау буенча җирлек территориясендә карарлар кабул итү һәм чаралар үткәрү, бу объектларга хокукы булган затлар турында белешмәләрне Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен юллау.»;

б) 5 өлештә «3 һәм 4 өлешләре» сүзләрен «3 өлеше» сүзләренә алмаштырырга;

3) $15^{1}$ статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 19 пункт өстәргә:

«19) алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыруга.»;

4) 16 статьяның 1 өлешендәге 35 пунктында «Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә» сүзләрен «федераль закон нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

5) $16^{1}$ статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 17 пункт өстәргә:

«17) алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыруга.»;

6) 17 статьяның 1 өлешендә:

а) 43 пунктта «Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә» сүзләрен «федераль закон нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 44 пункт өстәргә:

«44) элек исәпкә алынган күчемсез милек объектларына хокукы булган затларны ачыклау буенча шәһәр округы территориясендә карарлар кабул итү һәм чаралар үткәрү, бу объектларга хокукы булган затлар турында белешмәләрне Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен юллау.»;

7) $17^{1}$ статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 22 пункт өстәргә:

«22) алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыруга.»;

8) 33 статьяның 3 өлешендә «шәһәр һәм авыл җирлекләре» сүзләреннән соң «, шәһәр округлары» сүзләрен өстәргә, «тиешле җирлекләрнең» сүзләрен «тиешле муниципаль берәмлекләрнең» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә, моңа әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты, 2 пунктының «а» пунктчасындагы өченче һәм дүртенче абзацлары һәм 6 пунктының «б» пунктчасы керми.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты 2021 елның 7 июненнән үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының «а» пунктчасындагы өченче һәм дүртенче абзацлары һәм 6 пунктының «б» пунктчасы 2021 елның 29 июненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 08 апрель
№ 18-ТРЗ